РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.11.2024 № 901-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 23 маендагы 404-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба районы прокуратурасы протестын карап, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына, Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы карамагындагы түләүләр буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тану турында Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләп бетерүгә ышанычсыз дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 23 маендагы 404-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Башкарма комитетының кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 4 пунктның а) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында бюджет керемнәре администраторы белешмәсе;»;

**1.2.** 4 пунктның б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча бюджет керемнәре администраторының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында бюджет керемнәре администраторы белешмәсен;»;

**1.3.** 4 пунктның в) пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«амнистия турында акт яки штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча

бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;»;

**1.4.** 4 пунктның в) пунктчасында түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.».

**2.** 5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М. Р. Ишниязов